**СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер, Арский муниципальный район, 422031

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**«18» май 2023 ел** **№ 108**

**Җирле салымнар буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Арча муниципаль районы Яңа Кенәр муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле салымнар буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның түбәндәге өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, физик затның үлеменнән яки аның граждан процессуаль законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүеннән соң өч еллык срок тәмамлану, яки варисларның берсе дә мирас алырга хокуклы түгел яисә варисларның барысы да мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның барысы да мирасны алудан баш тартса һәм аларның берсе дә башка кеше файдасына баш тартуын күрсәтмәсә.

2. Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм бу салымнар буенча штрафларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 19.12.2022 №93;

- «Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм бу салымнар буенча штрафларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 11.10.2019 № 126;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында «Район җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин